ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БОЛЬШЕПОЛЯНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЗУР ПОЛЯНКА АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕНЕҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25.01.2024 № 3

**Мәет җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Күмү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә

**карар бирәм:**

1. Кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Зур Полянка авыл җирлегендә 8370,20 сум күләмендә 2024 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Үз көчен югалткан дип танырга:

- Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зур Полянка авыл җирлеге Башкарма комитетының 26.01.2023 ел, 4 нче номерлы Мәет җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында карары.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталындагы җирлек сайтында урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Зур Полянка авыл җирлеге Башкарма комитеты бинасында махсус мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә.

4. Бу карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

5.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз артыда калдырам

**Татарстан Республикасы Алексеевск**
**муниципаль районы Зур Полянка авыл җирлеге**
**Башкарма комитеты җитәкчесе** **Н.И.Александрова**



Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районының
Зур Полянка авыл җирлеге башкарма
комитетының 2024 елның 00
январьеннан
№ 0 карарына кушымта

**01.02.2024 тән мәет җирләү буенча хезмәтләр бәясенең гарантияләнгән исемлеге**

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтүләрнең бәясе (сум) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | _ |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3181,12 |
| 3. Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратка китерү | 1198,54 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3990,54 |
| Барлыгы | 8370,20 |

**01.02.2024 тән мәет җирләү буенча хезмәтләр бәясенең гарантияләнгән исемлеге**

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтүләрнең бәясе (сум) |
|---|---|
| 1.Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | _ |
| 2.Мәрхүмне киендерү (кәфеннәү) | 600,90 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2580,22 |
| 4. Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратка китерү | 1198,54 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3990,54 |
| Барлыгы | 8370,20 |